# Урта Курса туган якны өйрәнү музее




## Музейга сәяхәт

# Урта Курса туган якны өйрәнү музее



## Музейга сәяхәт


ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ
Хәзер музей Урта Курса урта мәктәбе бинасында.
Музейны беренче оештыручы-Бакиров
Хабибуллович
кадәр эшли.
1981-1992 елларда
музей житәкчесе булып
Галимжановна.
1992-1998 елларда музейны
Гарифуллин Вәгъдәнур
житәкли.
1999 нчы елда музейлар буенча үткәрелгән республика конферен-циясе делегатлары бездә кунакта.
Татар халкының милли йола һәм бәйрәм-нәренә багышланган кичәләр музейда үтә.
Музейның нумизматика бүлеге экскурсоводы-Камалиева Рәшидә.
Гыйльметдинова Альбина-музейның Госман Бакировка багышланган бүлеге экскурсоводы.
Экскурсовод Сәгыйтжанова Ландыш музейга килүчеләрне борынгы табылдыклар белән таныштыра.
ПОЧЕТНОЙ ГРАМОТОЙ
СВИДЕТЕЛЬСТВО
О ПРИСВОЕНИИ ЗВАНИЯ „ШКОЛЬНЫЙ МУЗЕЙ“
Благодарственное письмо
ТАНЫКЛЫК
МӘКТӘП МУЗЕЕ ИСЕМЕН БИРҮ ТУРЫНДА
СВИДЕТЕЛЬСТВО
О ПРИСВОЕНИИ ЗВАНИЯ ШКОЛЬНЫЙ МУЗЕЙ
СВИДЕТЕЛЬСТВО



Урта Курса мәктәбенең “Туган якны өйрәнү музее” на 1965 нче елда нигез салына. Мәктәпнең элекке директоры һәм тарих укытучысы Бакиров Гыйният Хәбибулла улы бу эштә башлап йөри. “1962 нче елда туристлык эше буенча Казанның Туристик базасы Ставропольдән килгән туристларны безнең мәктәпкә җибәрде. Менә шул туристлар белән мәктәп командасы болындагы палаткаларда бер атна яшәде. Шул вакытта оештырган эшләрне кунаклар бик ошатып киттеләр. Күп тә үтмәде, Турбазадан мәктәп директоры буларак, миңа рәхмәт хаты килде. Менә шуның белән канатланып, миндә тарих музее ачу теләге туды”, - дип сөйли Гыйният ага. Шуннан соң ул мәктәптә укучы төрле авыл балаларыннан отрядлар төзи. Музейга экспонатлар җыюда мәктәп укучылары, авыл халкы зур өлеш кертә.

http://aida.ucoz.ru

**Музейны беренче оештыручы - Бакиров Гыйният Хабибулла улы 1965 нче елдан 1981 елга кадәр эшли.**



http://aida.ucoz.ru

**1981-1992 нче елларда музей җитәкчесе булып тарих укытучысы Гайнуллина Фәния Галимҗан кызы эшли башлый.**



http://aida.ucoz.ru



**1992-1998 нче елларда музейны Гарифуллин Вәгъдәнур Рамазан улы җитәкли.**

http://aida.ucoz.ru



2000 нче елдан хәзерге көнгә кадәр музей җитәкчесе булып тарих укытучысы Шәфигуллин Наил Фаил улы эшли.

http://aida.ucoz.ru

# Краеведческий музей




Россия Федерациясе таныклыгы
(12.02. 2001 ел)




Татарстан Республикасы таныклыгы
(20 .08.1982 ел)




Татарстан Республикасы таныклыгы
(31.03. 1999 ел)


Музейның мәйданы : 36 м$^2$
Экспонатларның гомуми саны - 2028
11 экспозиция эшли. Вакытлы экспозицияләр юк. Фонд
Музей фонды төп һәм ярдәмче экспонатлардан тора.
Уникаль экспонатлар – 27
5 ел эчендә –төрле тематикадагы 430 экскурсия үткәрелде.

http://aida.ucoz.ru

# Авыл, колхоз һәм мәктәп тормышы




# Авыл тарихы








Моннан 500-600 еллар элек Югары Курса авылы Казан шәһәренең көнчыгыш ягына таба 70 км ераклыкка урнашкан. Элек бу авыл хәзерге урыннан 2 км ераклыкта “Йорт чишмәсе” дигән кечкенә елга буена утырган булган. Анда алар барысы 7 кеше булалар. Ниндидер сәбәпләр белән алар үз урыннарыннан күчәләр. Дүртесе Түбән Курсага, өчесе Югары Курсага күчәләр. Югары Курсага күчүчеләрнең берсе Җөрек исемле була. Югары Курса авылы урыны шактый биек тау чишмәсе, калын урманлык һәм тау асты сазлыктан торган. Бу урынга беренче мәртәбә килеп утыручы бабайлар тау башындагы агачларны кисеп, йорт урыннары хәзерләгәннәр.




http:///aida.ucoz.ru

# Авыл тарихы





Бу халыкларның төп кәсебе иген игү, хайван асрау, аучылык һәм бигрәк тә юкә сату булган. Алар зур итеп куптарып алган кәсне “курс” дип йөртә торган булганннар. Чөнки ул авыл кешеләре элекке заманнарда бөтен янәшә тирәгә танылып, курыс төшерү белән шөгыльләнгәннәр. Шул исемне авылга биреп, шуннан бирле авыл Курса исемендә калган.


Курса авыллары турында мәгълүмат 1602-1603 елларны эченә алган Казан өязе теркәү кенәгәсендә дә очрый. Эпиграфист Һарун Йосыпов Югары Курса зиратында XVI йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташлары тапкан. 1766-1861 елларда үткәрелгән Генераль ызанлау документларында күрсәтелгәнчә, Югары Курса авылы Черек чишмә янына утырган.





http://aida.ucoz.ru



"КУРСА"
КОЛХОЗЫ
КОМСОМОЛ
ОЕШМАСЫ
ТАРИХЫ


№1
Югары Курса
(«Батыр Курса»)
тарихы
ТАССР Верховный
Советы депутаты
Хайруллина
Альфинурга
багышлана


КОЛХОЗНЫҢ
МАКТАУЛЫ
КЕШЕЛӘРЕ
№2
Югары Курса
(«Батыр Курса»)
тарихы
№3
Югары Курса
(«Батыр Курса»)
тарихы


НӘРНЕ ИСКӘ АЛЫП.
ЧӘККӘ КҮЗЕҢ САЛ
Югары Курса
"БАТЫР КУРСА"
1929 НЧЫ ЕЛ
Урта Курса
"АВАНГАРД"
1942 НЧЕ ЕЛ
Түбән Курса
"КӨРӘШ КУРСА"
1931 НЧЕ ЕЛ
Алан
"АЛАН"
1929 НЧЫ ЕЛ
"АВАНГАРД"
1951 НЧЕ ЕЛ
С.Чокырча
Корайван
"МАРС"
"АВАНГАРД"
Ю.Курса
У. Курса
Т. Курса
Алан
"КУРСА"
1959 НЧЫ ЕЛ
"КУРСА"
"МАРС"
1990 НЧЫ ЕЛ
Корайван
С.Чокырча
Ю.Курса
У. Курса
Т. Курса
"АЛАН"
1993 НЧЕ ЕЛ
АЛАН
"КУРСА"
2002 НЧЕ ЕЛ
(ЯНВАРЬ)
"КУРСА"
2000 НЧЕ ЕЛ

# Мәктәп тарихы








Югары Курса авылы үзенең мәктәп-мәдрәсәләре белән тарихка кереп калган. Авылның бай, катлаулы үсеш тарихы бар. Чама белән алганда 1850 елларда Курса авылы уртасына агачтан 3-4 бүлмәле мәктәп салалар. Моны байлар эшләтә һәм анда Саба, Мамадыш, Балтач районнарыннан мулла һәм бай балалары килеп укыганнар. Йөзләрчә шәкертләр шунда торып укыганнар. Авылның ярлы катлау балалары бирегә керә алмаганнар.

1902 нче елдан Югары Курса авылында беренче баскычтагы татар мәктәбе эшләве билгеле. 1910 нчы елларда мулла Уразгилдеевның туганы Закир мәхдүм үлгәч, аның йортында кызлар мәдрәсәсе,

ә 1917-1920 нче елларда үзгәртелгән җидееллык мәктәп ачыла.









http://aida.ucoz.ru

# Мәктәп тарихы





1927 елгы пожар вакытында мәктәп бөтенләе белән янып бетә. Мәктәп урынына шуннан соң бер бина да салынмый.

1927 елдан 1930 елга кадәр авылда башлангыч мәктәп кенә була. Башлангыч мәктәпнең мөдире булып Галләмова Кафия эшләгән.


1935 нче елдан 1985 нче елга кадәр бу бина мәктәп буларак эшли. Хәзерге вакытта бу бинаның ишекләре һәркемгә ачык, чөнки ул мәчет буларак халыкка хезмәт итә.








http://aida.ucoz.ru



ТЕТРАДКА
КЛАССНЫЙ ЖУРНАЛ
ПАСПОРТ СЕМИЛЕТНЕЙ ШКОЛЫ
КНИГА ЗАПИСИ УЧАЩИХСЯ
НАРКОМПРОС РСФСР
КЛАССНЫЙ ЖУРНАЛ
ЧЕРНОВАЯ КНИГА
5 6 7 8 9




# Журнал киштәсе




**Класс журналы 1944-1945 ел**





Укытучылар һәм техник хезмәткәрләр турында мәгълүмат 1921 ел




Укучылар турында мәгълүмат китабы, 1948 ел

Уку әсбапларын һәм җиһазларын исәпкә алу
5 -10 класслар







Класс журналы
1944- 1945 ел




Каралама китабы
1936 ел




Җидееллык мәктәп паспорты 1946/47-1949/50 уку елы




Җидееллык мәктәп паспорты
1955/56-1959/60 уку елы




Дәфтәрләр
1945-1946 еллар




Язу өчен кара савыты


Госман Бакиров
1896-1982
Госман Бакиров



**Госман Фәтхулла улы Бакиров**

Татар балалар әдәбиятында озак еллар эшләгән язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Госман Фәтхулла улы Бакиров 1896 елда Югары Курса авылында туа. Атаклы авылдашы Габденнасыйр Курсави салып калдырган мәдрәсәдә укый. Ул, мәдрәсәдә укып белем алгач, Саба районының Югары Симет, Арча районының Чокырча һәм туган авылында мөгаллим булып эшли.

Г.Бакиров төп эше белән бергә балалар өчен пьеса, хикәя һәм повестьлар да яза, үзенең әсәрләрендә балалар тәрбиясенә аеруча зур игътибар бирә.

http://aida.ucoz.ru




Ул 1942 нче елда үзе теләп фронтка китә һәм Сталинградтан Польша чигенә кадәр арадагы сугышларда катнаша, гади солдаттан часть парторгы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. 1944 елда “За честь Родины” газетасына хәрби хәбәрче итеп билгеләнә. Фронтта күргәннәре турында “Партизан малай” исемле повесть яза. Язучының 20 дән артык китабы бар. “Утлы тегермән”, “Классташлар”, “Партизан малай”, “Сафа балалары”, “Укытучы апам” исемендәге әсәрләре рус, украин һәм чуваш телләренә дә тәрҗемә ителгән.

http://aida.ucoz.ru




Г.Бакировның шәхси баш киеме




Г.Бакировның шәхси күлмәге

http://aida.ucoz.ru

Г.Бакировның китаплары




Авылдаш язучыбызның исеме онытылмый.1996 нчы елның 12 нче мартында Курса авылында Госман Бакировның 100 еллык юбилее зурлап билгеләп үтелә. Кичәгә Г.Бакировның Казанда яшәүче кызы Суфия апа,әдипнең Казанда һәм авылда яшәүче бик күп туганнары кайта. Суфия апа мәктәпнең “Туган якны өйрәнү музее” на керә һәм әтисенең шәхси әйберләрен, фотоларын, берничә китабын истәлеккә калдыра.

Авылдашыбызга багышланган бүлектә аның тормышы, иҗаты турында материаллар, фотолары, басылып чыккан китаплары, шәхси китапханәсендәге 200 ләп китабы, аның нәселе турында шәҗәрә, киемнәре, көнкүреш техникасы урын алган.

http://aida.ucoz.ru


ШУШЫ ЯКТАН,
ШУШЫ ТУФРАКТАН БЕЗ.
Мәгърифәтче
Габденнасыйр
Курсави
ГАБДЕННАСЫЙР КУРСАВИ
1776 елда хәзерге Арча районы Курса авылында сәүдәгәр гаиләсендә туган. Башлангыч белемне Малмыж өязе Мәчкәрә авылы мәдрәсәсендә ала. Әмма зирәк, акыллы бу кеше үзлегеннән бик күп укый, камилләшә. Аңа да риза булмыйча, ул заманда гыйлем һәм мәгърифәт үзәге булган Бохарага китә. Анда белем алып, иске фикерле дин әһелләре белән бәхәскә керә,аларны кыю төстә тәнкыйть итә. Моның өчен галим якташыбызга үлем җәзасы билгелиләр. Ул аннан качып котыла һәм туган авылы Курсага кайтып,зур мәдрәсә ача. Үз янына шәкертләр туплап, мәгърифәтчелек фикерләрен тарата башлый. Тиз арада атаклы галим һәм әдип буларак таныла.
...деннасыйр Курсави
1812 елның көзендә ул абыйлары Габделхалыйк һәм Габделкәрим белән бергә хаҗ сәфәренә чыга. Истанбулда үләт чиренә юлыга, һәм өзәк та торчый аның гомере өзелә.
жирләнләр.

**Мәгърифәтче Габденнасыйр Курсави**

Курсавилар нәселе иҗтимагый тарихыбызда да, милли аңыбызда да шактый тирән эз калдырган. Габденнасыйр Курсави исә- Курсавиларның иң атаклысы. Ул 1776 елда хәзерге Казан губернасы Курса авылында сәүдәгәр гаиләсендә туган. Алар гаиләдә 4 малай булалар: Габделхаликъ, Габделкәрим, Габдерәшит һәм иң төпчеге – Габденнасыйр.

Габденнасыйрга унике яшь булганда, әтисе Ибраһим мулла дөнья куя. Әмма "зирәк малай" ны (аны авылда олылар шулай дип йөрткәннәр) апасы Мәрхәбә белән җизнәсе – Мәчкәрә авылы бае Габдулла Габдессәлам улы Үтәгәнев үз тәрбиясенә алалар.

Башлангыч белемне Габденнасыйр Малмыж өязе Мәчкәрә авылы мәдрәсәсендә ала. Зирәк акыллы бу егет үзлегеннән бик күп укый, камилләшә.




http://aida.ucoz.ru

Бохарада узган елларында ул һәрьяклап дини тәгълиматны өйрәнә, Көнчыгыш телләрен үзләштерү өстендә эшли. Иске фикерле дин әһелләре белән бәхәскә керә, аларны кыю төстә тәнкыйть итә. Моның өчен галим якташыбызга үлем җәзасы билгелиләр. Ул аннан качып котыла һәм, туган авылы Курсага кайтып, зур мәдрәсә ача. Үз янына шәкертләр туплап, мәгърифәтчелек фикерләрен тарата башлый. Тиз арада атаклы галим һәм әдип буларак таныла. Г. Курсави 1794-1808 нче елларда Югары Курса авылы мәчете имам-хатибы һәм үзе нигез салган мәдрәсәнең мөдәррисе була. Аның максаты-туган халкын рухи яңарту, аның аңын уяту, бәхетле итү. Ул елларда мәгърифәтче хәзрәт бик күп яза. Тик Курсавига тынгылык бирмиләр. Туктаусыз эзәрлекләүләргә түзә алмыйча, Г.Курсави туган якларын ташлап китәргә мәҗбүр була.




http://aida.ucoz.ru

## Г.Курсави һәм музей турында укучыларның фәнни-тикшеренү эшләре

Мәгърифәтче галимнең көчле акылы, тирән укымышлылыгы бик күпләрне сокландыра. Курсави уннан артык фәнни хезмәт язып калдырган. Алар арасында иң мәшһүре —“Әл - иршад лил-гыйбад» («Кешеләрне туры юлга өндәү»).    Габденнасыйрның китаплары күбрәк кулъязма рәвешендә киң тарала. Аның ислам фәлсәфәсенә караган “Китаб эл-ваих”, “Китаб эл-Нәсаих” дигән әсәрләре дә бар. Шулай ук ул һәфтиякне дә төрки телгә тәрҗемә итә һәм бу тәфсир 19 нчы гасыр ахырларына кадәр халык арасында киң тарала. Аның берничә кулъязма нөсхәсе Казан университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана.  Татар халкының рухи тормышындагы урынын билгеләп, Г.Ибраһимов аны “Туачак көн йолдызы” дип атады.




http://aida.ucoz.ru

# Нумизматика



Музейда төрле елларда чыгарылган бик күп кәгазь һәм металл акчалар бар.




http://aida.ucoz.ru

Җыелган акчаларның күбесе 1800-1880 елларга карый.




http://aida.ucoz.ru

Бакыр акчалар белән
бергә көмешләре дә
очрый. Өч, биш, ун
сумлыклар бар.




http://aida.ucoz.ru

XIX гасыр акчалары белән, Советлар Союзы елларыныкы да бар.




http://aida.ucoz.ru

1917-1961 еллар



http://aida.ucoz.ru

# 1961-1990 еллар



http://aida.ucoz.ru

1990-------- еллар



http://aida.ucoz.ru

Чит илдә чыгарылган акчалар да безне кызыксындыра. Монда немец маркасын да, Монголия, Болгариянең металл акчаларын да күреп була.




http://aida.ucoz.ru

# Нумизматика



Бу бүлектә орден-медальләр урнаштырылган. Монда Полтава сугышының 200 еллыгына 1909 елда чыгарылган, Кырым, Рус-Япон сугышына багышлап чыгарылган медальләр бар. Бирегә шулай ук герой шәһәрләргә багышлап чыгарылган значоклар, Бөек Җиңүгә багышланган юбилей медальләре, Кызыл Йолдыз орденнары да куелган.



http://aida.ucoz.ru

# Алар Ватанны сакладылар

Бу бүлек безнең өчен бик кадерле. Чөнки ул бүгенге бәхетле тормышыбыз өчен батырларча сугышкан Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм сугыштан әйләнеп кайта алмаган  авылдашларыбыз турында сөйли. Бөек Ватан сугышында безнең колхоз территориясенә кергән 6 авылдан 557 кеше катнаша. Ләкин аларның 299 ы сугыш кырларыннан әйләнеп кайта алмый.




http://aida.ucoz.ru

# Алар Ватанны сакладылар

Бүлектә Җиңүнең 20, 30, 35, 65, 70 еллыгы уңаеннан төзелгән альбомнар да урын алган.

"Алар Ватанны сакладылар" дигән бүлектә Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннарыбыз турында мәгълүматлар, Бөек Ватан сугышы ветераннарына багышланган стенд, тыл һәм сугыш ветераннарына багышланган альбомнар урын алган.







http://aida.ucoz.ru

# Алар Ватанны сакладылар

Әлеге бүлектә сугыштан килгән хатлар, шәхси документлар, грамота, мактау кәгазьләре бар.



http://aida.ucoz.ru

# Борынгы эш һәм хезмәт кораллары

Әлеге бүлектә без авылыбыз кешеләрендә сакланып калган һәм Бөек Октябрь революциясенә кадәр һәм аннан соң авыл кешеләре кулланган хезмәт кораллары белән таныша алабыз.







http://aida.ucoz.ru

Эш коралларыннан –кул тегермәне, туку орчыклары, жилпуч, җеп эрләгеч, агач көрәк, чабагач, урак, май язгыч, киле, киндер сугу station станогы, шулай ук тормыш-көнкүреш кирәк-яракларыннан төрле керосин лампалары, шахтер лампасы, керосинка, төрле йозаклар, сәгатьләр, кайчы, үлчәүләр, бизмән, кистән һ.б урын алган



http://aida.ucoz.ru

Фонарьларны авылдашларыбыз шахтадан кайтканда алып кайтканнар. Өйләрдә асылмалы лампалар да кулланылган.



http://aida.ucoz.ru

Бу хезмәт коралларыннан безнең әби-бабаларыбыз, авылдашларыбыз файдаланган. Экспонатлар безгә элекке тормышны дөресрәк күз алдына китерергә мөмкинлек бирәләр.



http://aida.ucoz.ru

# Халкыбызның күңел бизәкләре



Бу бүлектә шактый гына экспонатлар тупланган. Әбиләребезнең кул эшләреннән челтәр, чигүләр, сугылган тастымаллар, хатын-кызларның һәм ирләрнең милли киемнәреннән күкрәкчә.








http://aida.ucoz.ru

# Халкыбызның күңел бизәкләре











Калфак, изү тасмасы, бизәнү әйберләренән чулпы, беләзек-йөзекләр, чабата, бишек һ.б. күрергә була. Бу экспонатлар укыту-тәрбия процессында киң кулланыла.

http://aida.ucoz.ru

# Табылдыклар, сувенирлар









Бу бүлектә төрле

табылдыкларны күрергә

мөмкин.

http://aida.ucoz.ru

# Язма чыганаклар




Биредә гарәпчә язылган иске китаплар, газеталар, догалар урнаштырылган.




http://aida.ucoz.ru

# Бөек Ватан сугышына 70 ел



















http://aida.ucoz.ru

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт

